СОВЕТ ВОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ВОЙКИНОАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2026 с. Войкино № 20

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 16.11.2018 ел, № 106 карарына үзгәреш кертү хакында (үзгәрешләр белән 22.03.2019 ел, № 122, 18.11.2019 ел, №138; 05.08.2020 ел, №157; 29.07.2024 ел, №76 карары)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советының 16.11.2018 ел, № 106 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (үзгәрешләр белән 22.03.2019 ел, № 122, 18.11.2019 ел, №138; 05.08.2020 ел, №157; 29.07.2024 ел, №76 карары) түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 % карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларын, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Войкино авыл җирлеге башлыгы, Совет Рәисе** **Н.П.Шабутдинова**